**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены карары**
**(КАРАР)**

от «21» ноябрь 2019 г. № 2

**Мамадыш муниципаль районы**
**Отарка авыл җирлеге составына керүче**
**«Пятилетка» совхозы поселогы авылында гражданнар җыены**
**нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка” совхозы поселогында 2019 елның 21 ноябрендэ узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенен “Пятилетка” совхозы поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-“Пятилетка” совхозы поселогындагы суэтем башнясы коймасын урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-“Пятилетка” совхозы поселогындагы су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау (ремонт сетей водоснабжения) (материал, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- “Пятилетка” совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту;

« ӘЙЕ » « ЮК »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 343 кеше кертелгән;
халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 182 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» - 181 кеше тавыш бирде;
«Юк» - 1 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең «Пятилетка» совхозы поселогында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең «Пятилетка» совхозы поселогында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенен "Пятилетка" совхозы поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-"Пятилетка" совхозы поселогындагы суэтем башнясы коймасын урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-"Пятилетка" совхозы поселогындагы су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- "Пятилетка" совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту;

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
Советы рәисе _____________ Х.М.Минникаев